МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2.12.2021. г.Казань № 897.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 29 декабрендә 8781 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 сентябрендәге 488 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1-р номерлы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм

социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 сентябрендәге 488 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.09.2018 №904, 03.06.2019 №422, 14.11.2019 №1019, 25.06.2020 №460, 08.10.2020 №713, 17.12.2020 №861 реквизитлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
2 декабрендәге 897 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 сентябрендәге 488 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.»;

Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче

буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 нче бүлектә:

1.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне (алга таба – эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме) дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бердәмлеген, тулы, сыйфатлы булуын һәм тигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатында эшләнде.»;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Регламент билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча үзләренең вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында халыкны

эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре (алга таба – мәшгульлек үзәге) тарафыннан дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын, тәртибен һәм гамәлләр (административ процедуралар) эзлеклелеген билгели.»;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы порталында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.7 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.9 пунктның дүртенче абзацында «Федераль законның 2 ст. 1 п. » сүзләрен «Федераль законның 2 статьясының 3 пункты нигезендә тапшырылган» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте (алга таба – мәшгульлек үзәге) дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча бәяләмә бирү;

шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

### 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү ысулына һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайланган дәүләт хезмәте (аерым яки төркемле) күрсәтү формасына бәйле рәвештә билгеләнә. Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Мөрәҗәгать итүче белән дәүләт хезмәте күрсәтү датасын һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза мәшгульлек үзәгенә килгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең төркемле формасын сайлаган очракта, дәүләт хезмәте билгеләнгән тәртиптә расланган график буенча билгеләнгән чорда гражданнар төркемендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты тест (анкеталау) вакытын, тест (анкеталау) нәтиҗәләрен эшкәртү, бизнес-план әзерләү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасына кергән оешмаларга һәм учреждениеләргә мөрәҗәгать итү, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне исәпкә алмыйча 10 сәгатьтән артмаска тиеш.

2.4.3. Мәшгульлек үзәге тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында

карар эксперт советы тарафыннан бизнес-план буенча бәяләмә бирелгән көннән алып өч эш көне эчендә кабул ителә.

Эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында кабул итү турында кабул ителгән карар турында мәшгульлек үзәге эшсез гражданнарга карар кабул ителгән көннән башлап җиде эш көне эчендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта буенча яки мәшгульлек үзәгенә эшсез гражданин шәхсән килгән очракта) хәбәр итә.

2.5. Закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелгән гражданнар 90н номерлы боерык белән расланган форма нигезендә халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза яисә 90н номерлы боерык белән расланган форма нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс фрдәме күрсәтүгә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәшгульлек үзәге тәкъдименә ризалык тапшыралар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: мәшгульлек үзәгенә шәхси мөрәҗәгать итеп, почта аша, электрон почта аша, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә электрон документ формасында, шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып яки КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыны аша гариза тапшыру юлы белән.

Мәшгульлек үзәге органнары юлламасы буенча һөнәри белем алган яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнар өстәмә рәвештә һөнәри белем бирү курсы тәмамланганнан соң билгеләнгән үрнәктә бирелгән документ күчермәсен тапшыралар.

2.5.2. Мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә

ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торганын да, документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны.

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан факсимиль элемтә чараларын кулланып яисә электрон формада гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелә ала.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр алына:

инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан өземтә (алга таба – ИПРА);

инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмәләр;

организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кешенең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңлатыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында белешмәләр.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне үз инициативасы буенча бирергә хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турында гариза тапшырылган көнгә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәмен бирү өчен мәшгульлек үзәгенә билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаган (беткән) очракта яисә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турындагы гариза агымдагы елның 1 декабреннән соң алынса.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне вакытлыча туктатып тору өчен эшсез гражданин тарафыннан мәшгульлек үзәге юлламасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу нигез булырга мөмкин.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

документлар белән әлеге Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылуы;

эшсез гражданинда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турында килешүләр төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычларның булуы;

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өчен каралган бюджет акчалары хисабыннан билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар тарафыннан финанс ярдәменең (субсидиянең, дәүләт ярдәменең, юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда бер тапкыр финанс ярдәменең) элегрәк алынуы;

Эксперт советы тарафыннан эшсез гражданинның бизнес-планы буенча тискәре бәяләмә бирелүе.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Беренче тапкыр мәшгульлек үзәгенә килә торган мөрәҗәгать итүчеләр шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте буенча гариза чират тәртибендә тапшырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать иткән очракта, чират көтү вакыты 20 минуттан артмаска тиеш.

Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнар КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ белән мәшгульлек үзәге арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гариза КФҮдә теркәлгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның тапшырылуы тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте алдан язылу буенча күрсәтелә. Мөрәҗәгать итүче белән дәүләт хезмәте күрсәтү датасын һәм вакытын килештерү мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатьнең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

Гариза һәм документлар килгән көнне.

Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – мәшгульлек үзәгенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән

инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керептэшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мәгълүматның мөрәҗәгать итүче өчен хосусый яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү формасында мөмкинлекле булуы (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларыннан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән);

2) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза формаларын һәм башка документларны алу мөмкинлеген тәэмин итү, шул исәптән аларның күчермәләрен алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытын саклау;

4)дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, КФҮ аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайты аша;

5) инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачау итүче каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәкләрендә халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагымәҗбүри таләпләрнең, әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүе;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын үтәү;

3) әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеген саклау;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.

Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайты, (http://uslugi.tatarstan.ru/) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынырга мөмкин.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми.

